Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Каргалы авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре №4

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Каргалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 16 ноябрендә 16.00 сәгатькә «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Каргалы авылы, Фабричная ур.
2. 2020 елның 17 ноябрендә 16.00 сәгатькә «Ромашкино РНУ бинасында кызыл почмакта Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Михайловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Михайловка авылы.
3. 2020 елның 18 ноябрендә 16.00 сәгатькә «ГазпромТрансгазКазань» ҖЧҖ Константиновский ЛПУМГ бинасында урнашкан кызыл почмакта Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Михайловка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Михайловка авылы.
4. 2020 елның 19 ноябрендә 15.00 сәгатькә “Каргалы гимназиясе” МББМУнең актлар залында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Каргалы авылы, Нариманов ур., 47/а йорт.
5. 2020 елның 19 ноябрендә 16.00 сәгатькә мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Каргалы авылы, Чапаев ур., 7 «в» йорт.

6. Гражданнарның этаплап җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылында яшәүчеләр исемлеген 5 өлешкә бүләргә:

1) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргали авылында «Ак Барс» кошчылык комплексы» ҖЧҖ хезмәткәрләре исемлеге;
2) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргали авылында Ромашкино РНУ хезмәткәрләре исемлеге.
3) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргали авылы «ГазпромТрансгазКазан» ҖЧҖ Константиновский ЛПУМГ хезмәткәрләре исемлеге
4) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргали авылында «Каргалы гимназиясе» МБМУ хезмәткәрләре исемлеге
5) 1-4 исемлекләренә кертелмәгән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Каргали авыл җирлеге халкы.
7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2021 елда Чистай муниципаль районы Каргалы авыл җирлегенең Каргалы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, балачактан инвалидлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:
- Каргалы авылында авыл эчендәге юлларга вак таш салу (вак таш сатып алу)

**-** Кыр, Совет, Балакин урамнары буенча Каргалы авылында күп фатирлы йортларга канализация корылмалары төзү (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

« РИЗА» «КАРШЫ».

8. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Каргалы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
9. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Каргалы
авыл җирлеге башлыгы ________ М.А. Заһидуллин